ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 5 » март 2018 ел № 52

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның аларның вазыйфаи хәле яки хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм сатудан кергән акчаларны күчерү турында хәбәр итү хакында нигезләмәне раслау турында

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 2.1 статьясы нигезендә, Балтач муниципаль районы башлыгы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның аларның вазыйфаи хәле яки хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм сатудан кергән акчаларны күчерү турында хәбәр итү хакында нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә расларга;

2. Бәяләү комиссиясе турында нигезләмәне (2 нче кушымта) һәм аның составын (3 нче кушымта) расларга.

3. "Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның аларның вазыйфаи хәле яки хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм сатудан кергән акчаларны күчерү турында хәбәр итү хакында нигезләмәне раслау турында" 2014 елның 24 февралендәге 38 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны baltasi.tatarstan.ru районның рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район советы аппараты җитәкчесе И.С. Сабировка йөкләргә.

Балтач муниципаль районы
башлыгы Р.Р. Нотфуллин